КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 декабрь г.Казань № 1775

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте субъектларының оештыру, мәгълүмати, консультатив һәм методологик хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте субъектларының оештыру, мәгълүмати, консультатив һәм методологик хезмәттәшлеге регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына 60 көн эчендә түбәндәгеләрне билгеләнгән тәртиптә эшләргә һәм расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру функциясен башкаручы белгеч анкетасы формасын;

Татарстан Республикасында һәм аннан читтә була (үткәрелә) торган вакыйгаларны (чараларны) мәгълүмати яктырту буенча атналык медиаплан формасын;

Татарстан Республикасында һәм аннан читтә була (үткәрелә) торган вакыйгаларны (чараларны) мәгълүмати яктырту буенча атналык медиапланга кертелмәгән вакыйгага (чарага) мәгълүмати ярдәм күрсәтүгә заявка формасын;

анонсның бертип үрнәген;

пресс-релизның бертип үрнәген;

аккредитация кәгазе формасын;

массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләгәндә консультация һәм методологик ярдәм күрсәтүгә заявка формасын;

вакыйганы (чараны) мәгълүмати яктырту тәртибе буенча методик тәкъдимнамәләрне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру өчен

җаваплы белгеч компетенцияләре паспортын;

республика башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе турындагы нигезләмәнең үрнәк формасын.

3. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашучы оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашканда Регламентка нигезләнеп эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 декабрь, 1775 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте субъектларының оештыру, мәгълүмати, консультатив һәм методологик хезмәттәшлеге регламенты

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте субъектларының оештыру, мәгълүмати, консультатив һәм методологик хезмәттәшлеге регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте концепциясен раслау турында» 2025 ел, 9 февраль, 116 нчы карары белән расланган 2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

2. Регламентның төп максаты – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашырганда бердәм коммуникация пространствосын булдыру, шулай ук әлеге хезмәттәшлек тәртибен билгеләү юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру субъектларының (алга таба – Субъектлар) хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру.

3.Субъектлар – республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашучы башка органнар, оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре.

4. Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла:

белгеч – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру өчен җаваплы Субъект белгече;

медиаплан төзү – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмати яктыртуның медиапланнарын булдыру;

брифинг – Субъектларның рәсми вәкилләре белән ММЧ вәкилләренең нинди дә булса тар мәсьәлә буенча кыска рәсми мәгълүмат хәбәре белдерелә торган очрашуы;

матбугат конференциясе – ММЧ өчен Субъект эшчәнлегендә мөһим вакыйганы (чараны) анонслау яисә презентацияләү максаты белән үткәрелә торган чара;

спикер – ММЧ белән үзара хезмәттәшлек итәргә һәм аның рәсми позициясен игълан итәргә вәкаләтле Субъект вәкиле;

пресс-релиз – массакүләм мәгълүмат чаралары өчен мәгълүмати (яңа) хәбәр характерын йөртә торган, Субъектның агымдагы эшчәнлеге турында файдалы мәгълүмат бирә торган, формальләштерелгән документ.

5. Регламентның максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

Татарстан Республикасы халкына Субъектлар эшчәнлеге, мөһим вакыйгалар (чаралар), Татарстан Республикасында гамәлгә ашырыла торган программалар һәм проектлар турында үз вакытында, объектив һәм тулы мәгълүмат җиткерү;

социаль әһәмиятле һәм актуаль темалар буенча мәгълүмат әзерләү, аны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү мәсьәләләре буенча Субъектлар арасында мәгълүмати хезмәттәшлеккә бердәм якын килүне билгеләү;

халык өчен мәгълүмати материаллар әзерләгәндә аларның сыйфатын һәм аларны үз вакытында әзерләүне тәэмин итү, шулай ук Субъектларның массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек белән үзара хезмәттәшлек стандартларын камилләштерү һәм аларның үзара аралашу культурасын үстерү;

халык мөрәҗәгатьләренә һәм хәбәрләренә вакытында һәм сыйфатлы җавап бирүне тәэмин итү.

## II. Белгечләрне исәпкә алу һәм белгечләр компетенцияләрен үстерүдә Субъектларга ярдәм күрсәтү тәртибе

6. Агентлык Субъекталар тарафыннан Агентлыкка бирелә торган белгечләрне вазыйфага билгеләп кую турындагы мәгълүмат нигезендә белгечләрнең исәбен алып бара.

Белгечләрне исәпкә алу белгечләр алдына куелган бурычларны хәл итүнең кирәкле сыйфатын тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру барышында Субъекталар һәм Агентлык арасында эшлекле элемтәләр урнаштыру максатында алып барыла.

7. Субъектлар, белгечләр вазыйфасына билгеләнгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясенең шәхси мәгълүматлар турындагы законнарын үтәп, Агентлык тарафыннан раслана торган форма буенча белгеч анкетасын Агентлыкка тапшыра.

8.Белгечләрнең компетенцияләрен үстерүдә Субъектларга ярдәм күрсәтү максатларында Агентлык Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыру өчен җаваплы белгеч компетенцияләре паспортын һәм республика башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе турындагы нигезләмәнең якынча формасын эшли һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

## III. Мәгълүмати хезмәттәшлек

9. Субъектларның мәгълүмати хезмәттәшлеге түбәндәге кысаларда гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашырганда вакыйгаларда (чараларда) бергәләп катнашу;

бергәләп медиаплан төзү;

ММЧ рәсми сорауларына җаваплар әзерләү;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының

иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләргә ирешү максатларында мәгълүмати яктырту;

Татарстан Республикасында илкүләм проектларын гамәлгә ашыру барышын мәгълүмати яктырту;

Татарстан Республикасы халкы өчен социаль әһәмиятле темалар буенча уртак чаралар уздыру һәм программаларны гамәлгә ашыру.

10. Медиаплан төзүнең төрләре:

оператив;

атналык;

урта сроклы (еллык);

проект.

11. Оешмалар җәлеп ителгән һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан яктыртылган әһәмиятле чаралар үткәрелә торган чара темасы өлкәсендә идарә итүче республика башкарма хакимият органнары спикерлары катнашында үткәрелә.

## IV. Оператив медиаплан төзүне гамәлгә ашыру

12. Субъектларга Агентлык тарафыннан атналык медиаплан төзелгәннән соң (вакыйганың) чараның үткәрелүе турында билгеле булган һәм Татарстан Республикасы өчен әһәмияткә ия булган, Татарстан Республикасында һәм аннан читтә бара (үткәрелә) торган вакыйгаларны (чараларны) мәгълүмати яктыртуның атналык медиапланына (алга таба – атналык медиаплан) кертелмәгән вакыйгаларга (чараларга) карата оператив медиаплан төзү Агентлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агентлыктан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыйгаларны (чараларны) яктыртуда мәгълүмати ярдәм алырга кирәк булган очракта, Субъект, вакыйганы (чараны) үткәрү көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Агентлык тарафыннан раслана торган формалар буенча анонс һәм пресс-релизны теркәп, Агентлыкка атналык медиапланга кертелмәгән вакыйгага (чарага) мәгълүмати ярдәм күрсәтүгә заявка җибәрә.

13. Законнар һәм/яки хокукый актлар нигезендә видеога төшерү планлаштырыла торган оешма территориясендә видеога төшерүне гамәлгә ашыруга рөхсәт таләп ителгән очракта, заявкага шулай ук билгеләнгән тәртиптә таныкланган видеога төшерүне гамәлгә ашыруга рөхсәт күчермәсе теркәлә.

Субъекты ММЧ вәкилләрен аккредитацияләгәндә Агентлыкның ярдәме кирәк булган очракта, Субъект, вакыйганы (чараны) үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Агентлыкка Агентлык тарафыннан раслана торган форма буенча аккредитация кәгазе белән заявка җибәрә.

14. Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры катнашындагы вакыйгаларны (чараларны) анонслау, мондый чараларга журналистларны чакыру һәм аккредитацияләү, Татарстан Республикасы Матбугат хезмәте белән килештереп, Субъекталар тарафыннан башкарыла.

## V. Атналык медиаплан төзүне гамәлгә ашыру

15. Агентлык тарафыннан, һәр җомгадан да соңга калмыйча, Агентлык раслаган форма буенча атналык медиаплан төзелә.

16. Атналык медиаплан түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

чараны уздыру датасы (чоры), вакыйга үткәрү датасы (чоры);

вакыйга (чара) исеме һәм аның кыскача тасвирламасы;

вакыйга  (чара) өчен җаваплы Субъект исеме;

Агентлык тарафыннан вакыйганы (чараны) мәгълүмати яктырту максатларында күрсәтелә торган мәгълүмати ярдәм чаралары (кирәк булганда).

17. Атналык медиаплан Агентлык тарафыннан түбәндәге юллар белән төзелә:

вакыйгаларны (чараларны) атналык медиапланга кертү турында Субъектлардан тәкъдимнәр җыю;

Агентлык тарафыннан атналык медиапланга мөһим вакыйгаларны (чараларны) кертү.

18. Вакыйганы (чараны) атналык медиапланга кертү максатларында Субъектлар һәр пәнҗешәмбе 18 сәгать 00 минуттан да соңга калмыйча вакыйгаларны (чараларны) атналык медиапланга кертү турында Агентлыкка тәкъдимнәр җибәрә. Әгәр Субъект вакыйганы (чараны) атналык медиапланга кертү турындагы тәкъдимне күрсәтелгән сроктан соңрак җибәрсә, Агентлык мондый тәкъдимне карамыйча калдырырга хокуклы.

19. Агентлык Субъектларга атналык медиапланга кертелгән вакыйгаларны (чараларны) яктыртуда мәгълүмати ярдәм күрсәтә. Агентлык тарафыннан мәгълүмати ярдәм күрсәтү түбәндәге чаралардан гыйбарәт:

матбугат конференцияләре, брифинглар, «түгәрәк өстәлләр», әңгәмәләр, очрашулар һ.б. оештыру;

журналистларны аккредитацияләүдә ярдәм күрсәтү;

чараларны уздырганда массакүләм мәгълүмат чараларын координацияләү.

20. Агентлык, һәр җомгадан да соңга калмыйча, атналык медиапланга кертелгән вакыйгаларны (чараларны) өстенлекле тәртиптә яктыртуны тәкъдим итү максатларында атналык медиапланны Татарстан Республикасының дәүләт ММЧ редакциясендә, устав капиталында Татарстан Республикасының катнашу өлеше 50 проценттан арткан, гамәлгә куючы булган юридик затлар редакциясендә, башка массакүләм мәгълүмат чаралары (кирәк булганда) редакциясендә җибәрә.

## VI. Урта сроклы (еллык) медиаплан төзүне гамәлгә ашыру

21. Урта сроклы (еллык) медиаплан төзү бер ел срок белән гамәлгә ашырыла.

22. Субъектлар, агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча, Агентлыкка Татарстан Республикасында һәм аннан читтә бара (үткәрелә) торган вакыйгаларны (чараларны) мәгълүмати яктырту медиапланына (алга таба – еллык медиаплан) вакыйгаларны (чараларны) кертү турындагы тәкъдимнәр тапшыра.

23. Еллык медиаплан түбәндәгеләрне үз эченә ала:

чараны якынча үткәрү датасы (чоры), вакыйганың якынча булу датасы (чоры);

вакыйга (чара) исеме һәм аның кыскача тасвирламасы;

вакыйга (чара) өчен җаваплы Субъект исеме.

24. Агентлык, агымдагы елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча, Субъектлардан кергән тәкъдимнәр нигезендә еллык медиапланны раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын (алга таба – проект) эшли һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 5 декабрь, 563 нче карары белән расланган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карап тикшерүгә җибәрә.

25.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында проектны карап тикшерү Регламентның 24 нче пункты нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты агымдагы ел ахырына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының еллык медиапланны раслау турындагы боерыгын кабул итә.

26. Еллык медиапланда каралган вакыйгалар (чаралар) Агентлык тарафыннан тиешле атналык медиапланга кертелә.

## VII. Проект медиаплан төзүне гамәлгә ашыру

27. Проект медиапланын төзү федераль, республика, халыкара масштабтагы әһәмиятле вакыйгаларны (чараларны) җентекләп яктырту максатларында гамәлгә ашырыла.

28. Федераль, республика, халыкара масштабтагы әһәмиятле вакыйгаларны (чараларны) яктыртканда Субъектларның мәгълүмати хезмәттәшлеге тиешле вакыйганы (чараларны) мәгълүмати яктыртуны оештыру чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырыла, аның составына Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Агентлык, җәлеп ителгән башка Субъектлар вәкилләре, шулай ук кирәк булганда башка кызыксынучы затлар керә.

## VIII. Вакыйгаларны (чараларны) яктыртканда Субъектларның Агентлык белән конструктив һәм методологик хезмәттәшлеге

29. Агентлык үзара хезмәттәшлек кысаларында Субъектларга вакыйгаларны (чараларны) яктыртканда ММЧ белән эшләгәндә консультатив һәм методик ярдәм күрсәтә.

30. Атналык медиапланга кертелгән вакыйгаларны (чараларны) яктыртканда массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләгәндә консультатив һәм методологик ярдәм алу максатларында Субъект Агентлык тарафыннан расланган форма буенча Агентлыкка ММЧ белән эшләгәндә консультация һәм методологик ярдәм күрсәтүгә заявка җибәрә.

31. Агентлык өч эш көне эчендә Регламентның 30 пунктында каралган заявканы карап тикшерә. Заявканы карап тикшерү нәтиҗәсе – Агентлык тарафыннан вакыйганы (чараны) мәгълүмати яктырту формасы буенча һәм тәртибендә

Субъектка тәкъдим бирү. Тәкъдим язма рәвештә җибәрелергә мөмкин, шулай ук Агентлык хезмәткәре тарафыннан Субъектка телдән консультация үткәрелергә мөмкин.

32. Вакыйгаларны (чараларны) яктыртканда ММЧ белән эшләгәндә алар белән хезмәттәшлек итмичә Субъектларга консультатив һәм методологик ярдәм күрсәтү максатларында, Агентлык вакыйганы (чараны) мәгълүмати яктырту тәртибе буенча методик тәкъдимнәр эшли һәм аны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

---